

Яна ел – ул балалар да, олкәннәр дә котеп һәм сагынып ала торган бәйрәм. Яна елны зарыгып котеп алабыз һәм аны матур итеп каршыларга әзерләнәбез. Әнә, Саранск башкалабыз белән бергә, Мордовия авылларында һәм шәһәрләрендә дә бәйрәм рухы инде: бизәлгән чыршылар, торле тосләре белән жемелдәvче утлар, ясалма катоклар... Һәркем кулыннан һәм момкинлегеннән килгәнчә фантазиясен эшкә жиккән. Россия һәм Мордовия кvләмендә торле-торле онлайн-чаралар да планлаштырылган. Хезмәт итvчеләр очен Яна ел алдыннан бер кvнелле хәбәр бар. Мордовия Респуб ликасы Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Артем Здунов дәvләт хезмәткәрләре очен шимбә, 26 декабрьдә кыскартылган эш коне булачак боерыкка кул куйган. Ял 31 декабрьгә кvчерелә.

Республиканын барлык дәvләт органнары, жирле vзидарә органнары, шулай ук Мордовия территориясендә урнашкан оешмалар житәкчеләренә хезмәткәрләрнен эш вакытын югарыда карар буенча оештырып, 31 декабрьдә ял оештырырга тәкъдим итә.

Мордовия Республикасы Дәv-ләт Жыелышы Рәисе Владимир Чибиркин «Теләкләр чыршысы» хәйрия акциясендә катнашты. Ул «Россия – момкинлекләр иле» Президент платформасына керvче «Минем белән хыяллан» Ботенроссия проекты кысаларында уза. 11 декабрьдә, РФ Конституциясе коненә багышланган тантаналы кабул итv вакытында, Владимир Чибиркин бәйрәм чыршысыннан берничә открытка алды, анда Мордовиянен яшь кешеләре vз хыяллары белән уртаклашты. Яна ел бәйрәмнәре алдыннан РМ Дәvләт Советы Рәисе балаларнын теләкләрен vтәячәк.

Быелгы шартларда чыршы бәйрәмнәре зурлап vтелмәсә дә, балалар бик тә котә аны. Ойләрендә чыршы бизи, тәрәзәләргә vз куллары белән яратып ясаган кар бертекләре кундыра, утлар кабызыла... Мәсәлән, 13нче декабрьдә Рузаевка районы Татар Пешлә мәдәният йортында, Елизавета Владимировна Мурашова житәкчелегендә эшләп килгән «Чудеса творения - Фантазия» тvгәрәгендә, бергәләп vз куллары белән чыршы уенчыклары эшләгәннәр. Үзен ясап элгән уенчык бигрәк кадерле була бит. Бу уенчыкка монәсәбәт тә vзгәрә.

Шулай ук НТМ оештырган «Яна ел открыткасы» дигән чарада да Татар Пешлә авылы балалары vзләренен соекле әниләрен, гаиләләрен, дусларын бәйрәм белән котлап ин жылы сvзләрен видеода янгыратканнар. Мәсәлән, Зульфия Мансур кызы Зубрилкинаны кыздары Арина, Татьяна һәм Амелина ихластан котлап матур чыгыш ясаганнар. Ә әниләре, билгеле, Яна ел бәйрәмендә тапшырырга дип, балаларына бvләкләр әзерли, тәмлvшкалар пешереп сыйларга жыена.

Кичке башкалабыз бик матур. Саранск-нын һәрбер районында катоклар эшли. Шунда балалар рәхәтләнеп кондез дә, әти-әниләре белән кич тә тимераякта шуа. Һәркем кулыннан һәм момкинлегеннән килгәнчә фантазиясен эшкә жиккән. Россия һәм Мордовия кvләмендә торле-торле онлайн-чаралар да бу бәйрәм хормәтенә планлаштырылган. Барыбыз да исән-сау булып, матур гына Яна елны каршылыйк.

Наилә НАСЫРОВА